# Әбиемнең сандыгы

## Бабушкин сундук

Презентацияне төзеде:
Әлки районы Чуаш Кичүе урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нургазизова Зөһрә Шамил кызы

2013 ел

# Бизәнү әйберләре ясау сәнгате





Бизәнү әйберләренең кайберләрен (алка,йөзек, беләзек,калфак, муенсалар-ны) көн дә кигәннәр, ә кайберләрен (хәситә, изү, яка чылбырларын) бәйрәм көннәрендә, кунак – төшем килгәндә, сәяхәткә чыкканда такканнар.

Татар ювелирлары бизәнү әйберләрен ясау һәм аларга бизәк төшерү өчен төрле чаралар кулланганнар. Болар көмеш каралту,уеплау, тирән итеп һәм яссы чоку ( тойма), басма, кыйммәтле металлар белән инкрустацияләү (корлау), асылташларга уеп бизәк ясау һәм уеп таш кисү,кою,яссы һәм төерле бизәкләр төшерү.

# Чигү



Казан татарлары сәнгатендә чәчәк бәйләмнәре рәвешендә композиция-ләр киң таралган. Чәчәк бәйләмнә-рен бик тә нечкә һәм нәфис бөгел-гән сабаклар һәм эре – эре чәчәк-ләр белән ясыйлар, алар арасына вак чәчәк мотивлары һәм бөреләре урнаштырыла. Бер үк сабакта еш кына тюльпан, георгин, канәфер, роза, мәк, ромашка һ.б. Чәчәкләрнең мотивларын күрергә була.

Чигелгән әйберләрдә кайвакыт кош, бал корты, күбәләк сурәтләре очрый, алар чәчәк – үсемлек бизәгенә якынайтып бирелә.

# Бизәкләп туку



Татар кызлары һәм хатыннары үзләренә бирнә, туган –тумачаларына һәм кияүләренә , сабантуйга бүләкләр, йорт өчен чаршаулар, кашагалар, сөлгеләр әзерләгәннәр.

Оста куллар бизәкләп туку техникасының барлык төрләрен белгәннәр. Болар – чүпләм, төсле чүпләм, кыялап сугу һәм аеруча традицион булган асалап сугу. Кызыл яки алсу төстәге борынгы сөлгеләргә төшерелгән эре –эре , катлы –катлы геометрик бизәкләр нигездә буй –буй булып сөлге читләрендә урнаштырылган: төп буй киң булып, як –якта таррак бизәкләр ясалган. Өске һәм аскы буйдагы бизәкләр гадәттә бер –берсен кабатлап килгән.

# Күнгә бизәк төшерү сәнгате





Бизәкле күн читекләр, туфлиләрне төсле йомшак күн сафьяннан, бераз катырак булган юфтьтән, кайвакыт кәҗә тиресеннән тегәләр.

Күнне салават күперенең барлык диярлек төсләре-нә маналар, аннары, бизәк төшергәндә, трафаретка салып кисәләр. Күн кисәкләреннән ясалган бизәкләрне мозаика тәртибендә урнаштырып, ефәк, кайвакыт алтын һәм көмеш җепләр белән тоташтырып тегәләр. Мозаика бизәге нигезендә өч икеяфраклык, пальмет-калар, розеткалар; йөрәк, дулкын, атлама; лаләсыман, мөгезсыман, болытсыман сурәтләр ята. Мозаикада күптөрле вариантларда кыңгырау чәчәк, тюльпан ( лалә) кулланыла. Бизәкләргә кәкре сызыклык, формаларның йомыклыгы һәм бер форманың икенчесенең эченә кертелүе , контурларны бөтерелгән төсле җепләрдән ачык итеп кабартып күрсәтү хас.

Күннән бизәкләп тегелгән әйберләр һәрвакыт кул белән эшләнгән һәм шуңа күрә уникаль булган.

# Нәфис керамика



Борынгы заманнарда ук болгар керамикачылары бик күптөрле савытлар (кувшиннар, җамаяклар, комганнар), уенчыклар ясаганнар. Яндыруның төрле фазаларын һәм югары температураларын кулланып, осталар куе көрән төстән алып тötенсыман соры төскә кадәр үзенчәлекле төс гаммасын булдырганнар. Савытларны ангоб ( ак, кызыл, соры балчык), үтә күренмәле (ачык яшел төстән алып караңгы, кара диярлек төскә хәтле) лак белән каплау һәм буй –буй итеп шомарту киң таралган. Чүлмәкчеләр иҗатының үзенчәлекле булуы төрле кошлар һәм хайваннар сурәтләре төшерелгән савытларда да чагылыш тапкан. Түгәрәк формадагы бу сурәтләр кувшин –комганнарның тоткаларын һәм борыннарын бизәп торган.

# Ювелирное искусство



Одни украшения (серьги, кольца, браслеты, накосники, бусы и ожерелье) были повседневными, другие ( перевязи, нагрудники, воротниковые подвески) использовались по праздничным дням, при гостях, в поездках…

Татарские ювелиры обладали разнообразными средствами изготовления и орнаментации украшений. Чернение по серебру (“каралту”), гравировка (“уеплау”), глубокая и плоская чеканка (“тойма”), штамповка (“басма”), инкрустация драгоценными металлами (“ корлау”), гравировка на самоцветах и искусство огранки камней (“уеп таш кисү”), литье ( кою), плоская и бугорчатая скань.



# Вышивка






Композиция в виде цветочного букета получили наибольшее распространение в искусстве вышивки казанских татар. Букеты делались с очень тонкими и изящно изогнутыми стеблями и крупными цветами, между которыми нередко разбрасывались мелкие цветочные мотивы и бутоны. Часто на одном стебле можно видеть мотивы тюльпанов, георгинов, роз, маков, ромашек и др. , а также различного рода листьев.

В вышитых изделиях иногда встречаются изображения птиц, пчел, бабочек, приближенные к цветочно – растительному узору

# Узорное ткачество



Издавна татарские девушки и женщины проводили долгие часы за ткацким станком, готовя себе приданое, подарки родственникам и жениху, призы для сабантуев, «мягкую утварь » для дома ( занавески – чаршау, подзоры – кашага, полотенца).

Мастерицы овладели всеми видами техники узорного ткачества: браного ( «чүпләм»), выборного ( «төсле чүпләм»), многоремизного ( « кыялап сугу») и наиболее традиционного -- закладного тканья ( «асалап сугу»). Крупные многоступенчатые геометрические фигуры на приглушенно – красном или светло – малиновом фоне старинных закладных полотенец заполняют бордюры, которые в основном располагаются полосами: основным – широким и по сторонам – узкими бордюрами. Узоры верхней и нижней полосы обычно повторяют друг –друга.

# Искусство кожаной мозаики





Узорные кожаные ичиги, туфли изготовлялись из мягкого цветного сафьяна, более жесткой юфти, иногда – козловой кожи.

Кожа окрашивалась почти во все цвета радуги, затем, при создании узора, она прорезалась по орнаментальным трафаретам. Узоры из кусочков кожи составлялись в технике мозаики с одновременной сшивкой и расшивкой орнаментальных мотивов шелковыми, иногда золотыми и серебряными нитями.

Основных мозаичных орнаментов три: двулистники, пальметки, розетки; мотивы сердечка, волны, скобы; лотосовидные, роговидные, облокообразные изображения. В мозаике во множестве вариантов представлены: колокольчик, тюльпан. Для узоров характерны криволинейность, замкнутость форм и вписывание одних фигур в другие, четкая очерченность контуров рельефными швами из цветных крученых нитей.

# Художественная керамика



В давние времена булгарские керамисты производили самые разнообразные сосуды ( кувшины, хумы, кумганы), игрушки. Используя различные фазы обжига и высокую температуру, мастера создавали своеобразную цветовую гамму: от темно коричневого до дымчато – серого. Широкое распространение получило покрытие сосудов ангобом

( белой, красной, серой глиной), прозрачной поливкой ( от светло –зеленого до темного, почти черного цвета) и лощение в виде полос. Самобытность творчества гончаров проявлялось в « зооморской» керамике – сосудах с изображениями различных птиц и животных. Вылепленные в круглой скульптуре, они украшали ручки и сливные носики кувшинов, кумганов.

# Әби-бабаларның өе

Челтәр – челтәр ак пәрдәләрсез, бизәкле – чәчәкле чаршауларсыз, чигүле сөлге, ашъяулыкларсыз болай ук ямьле булмас иде бу өй эче. Аның түрендә төп хуҗасы булып сандык тормаса, нәрсәдер җитешмәгән кебек була. Әбиләрнең үз сандыкларындагы буыннан –буынга тапшырыла торган кадерле байлыкны караганда, без тарихыбыз белән генә түгел, татар халкының милли сәнгате белән дә танышабыз. Милли сәнгатебезнең һәр төрендә дә чәчәкле үсемлек бизәкләре барлыкка килә. Сез дә, кадерле балалар, үзегезнең кечкенә генә «сандыгыгызны» ачыгыз, сокланыгыз, чөнки беркем дә моннан матуррак бизәкләр таба алмый. Халкыбызның йөз аклыгы бит сездә.

Безнең милли сәнгатебезне дәвам итүчеләр ишәйгәннән – ишәя бара, шуңа күрә ул гореф – гадәтләребез яшәр һәм чәчәк атар.



Кулланылган әдәбият:

Нурзия Сергеева “Әбиемнең сандыгы”

Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1995





# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!